Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Кадыровского
сельского поселения Заинского
муниципального района

ул. Молодежная , д. 1, с. Кадырово,
Заинский район, 423513

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Кадер авыл җирлеге
Башкарма комитеты

Яшьләр урамы, 1 нче йорт, Кадер авылы,
Зәй районы, 423513

Телефон, факс 63-3-18. Электронный адрес: Kadir.zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**31.01.2020** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләрен раслау турында**

1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 нчы номерлы «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы «2020 елда пособиеләр, компенсацияләр һәм компенсацияләр күләмен раслау турында» карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2020 елның 01 февраленнән, 1нче кушымта һәм 2нче кушымта нигезендә, 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М. Нуруллин

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Кадер авыл җирлеге Башкарма
комитетының
31.01.2020 ел № 2
карарына 1нче кушымта

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлегендә 2020 нче елның 1 нче февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтләрнең исемлеге** | **Хезмәтләрнең бәясе (сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 2 343,73 |
| 3. Мәетне (калдыкларны) зиратка илтү | 944,51 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 836,62 |
| Барысы | 6 124,86 |

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Кадер авыл жирлеге Башкарма
комитетының
31.01. 2020 ел № 2
карарына 2нче кушымта

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Кадер авыл жирлегендә
2020 нче елның 1 нче февраленнән жирләү буенча
гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне төрү (облачение тела) | 628.31 |
| 3. Табутны һәм жирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 1 715.42 |
| 4. Мәетне (калдыкларны) зиратка илтү | 944.51 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 836.62 |
| Барысы | 6 124.86 |